ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е КАРАР

2021 елның 27 сентябре № 20

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Туктар-Урдаласы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 27 декабрендәге 16 номерлы карарына һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Туктар-Урдаласы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яисә килүче гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу" муниципаль хезмәт күрсәтү регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 27 декабрендәге 16 номерлы карарының преамбула елешендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Туктар-Урдаласы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 27 декабрендәге 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Туктар-Урдаласы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яисә килүче гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу" муниципаль хезмәт күрсәтү регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре»;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет ур., 98 адресы буенча урнашкан административ бинада, Совет ур., 103 йорт, Карагай авылы, Тельман ур., 31 йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
"Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Ә.Әхмәтова